# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Уразай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27 ноябрь 2024 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 27 нче ноябрендэ түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, кондезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр очен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнэлту белэн килешэсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны( Уразай белән урамнарны яктырту җайланмасын)ремонтлау;
- Уразай авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын ремонтлау, су үткәрү торбаларын урнаштыру);
- Уразай авыл җирлеге территориясен тозекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп-чар җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту);
-Уразай авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа, янгын җиһсәләре сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 576 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 291 .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 291, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Уразай _авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлту белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны( Уразай белән урамнарны яктырту җайланмасын)ремонтлау;

- Уразай авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын ремонтлау, су үткәрү торбаларын урнаштыру Подгорная, Речная урамнарында);

- Уразай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп-чар җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту);

-Уразай авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа, янгын җиңсәләре сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы _______________ А.М.Шэрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)

УРАЗАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ